КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 8 май г.Казань № 681

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 март, 133 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 15 март, 133 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 гыйнвар, 69 нчы; 2022 ел, 30 июль, 736 нчы; 2022 ел, 21 ноябрь, 1245 нче; 2023 ел, 4 февраль, 98 нче;

2024 ел, 19 март, 162 нче; 2025 ел, 27 март, 175 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

46 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

52 пунктның беренче абзацында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин